УДК 821.512.145-2

***Ф.Х. Миңнуллина***

# К. ТИНЧУРИН ДРАМАТУРГИЯСЕНДӘ ШӘХЕС ФАҖИГАСЕ

В статье поднимается вопрос отражения прошлого татарского народа в произведениях К. Тинчурина. Особое внимание уделено изучению драм автора «Сүнгән йолдызлар», «Зар», «Ил», где отражается трагедия человека, на долю которого выпали суровые жизненные испытания.

**Ключевые слова:** драма, судьба татарского народа, конфликт, трагическое, личность.

Кәрим Тинчурин катлаулы, кискен борылыш елларында иҗат итеп, татар совет драматургиясен, театрын үстерүгә зур өлеш керткән каләм иясе. XX гасырның 10 нчы елларында каләм тибрәтә башлап, 30 нчы еллар уртасына кадәр дәвам иткән иҗат юлында ул бай мирас калдырган шәхес. К. Тинчурин, күпкырлы әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлек алып барса да, киң җәмәгатьчелеккә, беренче чиратта, татар драматургиясенең иң күренекле вәкиле буларак билгеле. Ул бер-бер артлы «Хәләл кәсеп» (1910), «Шомлы адым» (1912), «Беренче чәчәкләр» (1913), «Назлы кияү» (1915), «Ач гашыйк» (1916), «Җилкуарлар» (1916), «Соңгы сәлам» (1917), «Йосыф белән Зөләйха» (1918), «Сакла, шартламасын!» (1918), «Казан сөлгесе» (1923), «Американ» (1924), «Хикмәтле доклад» (1928), «Сүнгән йолдызлар» (1923), «Зәңгәр шәл» (1926), «Җилкәнсезләр» (1925) «Ил» (1927) пьесаларын әдәбият мәйданына чыгара. Драматург иҗатында илне якты киләчәккә өметләндергән көрәш рухы, халыкның яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре, авыл кешесенең өмет-хыяллары чагылыш таба. К. Тинчурин пьесаларында тормышта үз урыныңны табу, халыкка хезмәт итү, искелек белән яңалыкның, өлкән буын белән яшьләрнең, шәхес белән җәмгыятьнең үзара каршылыгы үзәк урынны били. Авторның «Беренче чәчәкләр», «Зар», «Ил», «Соңгы сәлам» әсәрләре заман белән бәйле фикри-әхлакый кыйммәтләр, дөньяга карашлар үзгәрешен, татар кешесенең киң борылышлар чорындагы гыйбрәтле дә, шул ук вакытта фаҗигале дә язмышын тарихи контекстта тергезүе белән үзенчәлекле. Драматург иҗатында даими рәвештә халкыбызның милли язмышы белән бәйле булган актуаль мәсьәләләр күтәрелеп тора. Мәсәлән, «Беренче чәчәкләр» драмасының үзәк герое Хәмит, мәдрәсәдә алган белем, тәрбия белән канәгатьләнмичә, русча укырга алына. Киләчәктә халыкка хезмәт итү теләгән тормышка ашыру максаты белән университетка укырга керә, врач булырга тели. Кызганыч ки, укуы өчен түли алмый, шул сәбәп белән уку йортыннан

куылачагын белгәч, авыруы көчәеп, туберкулездан үлә. Гомумән, К. Тинчурин пьесаларында шәхес иреге, социаль тигезсезлек, мәхәббәт һәм бәхеткә хокук, милләт язмышы, үткән тормышның фаҗигале яклары тасвирлана.Татар кешесенең гаять авыр шартлардагы яшәеше, кыерсытылуы алгы планга чыга. М. Арсланов билгеләгәнчә: «Күпкырлы иҗади шәхес буларак, аны иң беренче милли проблемалар, татар кешесенең эше, яшәеше, Русия җирлегендәге башка милләт вәкилләре белән мөнәсәбәте кызыксындыра» [Арсланов, 2007, б. 9]. Мәсәлән, әдипнең «Соңгы сәлам» (1917) драмасында яшь сәүдәгәр Вахит рус кызы Ольгага гашыйк була. Ольганы сайлау – аның өчен гаиләсеннән китү генә түгел, ә милли яшәешеннән, милләтеннән ваз кичү белән бер. Ләкин герой тормыш иптәшен, авыру баласын, карт анасын, үзен чорнап алган милли яшәешне ташлап китми. А. Әхмәдуллин сүзләре белән әйткәндә, драмада хис һәм акыл бәрелешендә шәхес ялгызлыгы калкып чыга [Әхмәдуллин, 2002, б. 92 ]. Ике ут арасында калган, яшәү мәгънәсе хакында уйланган, әрнү, газаплану кичергән Вахит рухи газапта – килеп туган каршылыкны чишә алмау, якыннарыннан читләшү, үз эченә йомылу аны үз-үзенә кул салуга этәрә. Биредә шәхес, гаилә трагедиясе милләт фаҗигасе буларак ачыла. Әсәр башында драматург тарафыннан телгә алынган Вахитның авыру баласы да, егет күңелендә барган хисләр бәрелешен, әрнү, газаплану халәтен белдерә.

К. Тинчуринның мәхәббәт өчпочмагына нигезләнгән «Сүнгән йолдызлар» фаҗигале драмасында вакыйгалар Беренче бөтендөнья сугышы вакытында бара. Ф. Бәширов сүзләре белән әйткәндә: «Драматург бу әсәрләрендә үзенең геройларын катлаулы тарихи шартларда тасвирлый. Шуңа да әлеге әсәрләрне халык драмасы дип атау, һичшиксез, дөрес булачак» [Бәширов, 2007, б. 7]. «Сүнгән йолдызлар»да геройлар фаҗигасе ил фаҗигасе белән бергә үрелеп бара. Бу вакыйга Җиһанша карт сүзләрендә дә чагыла: «Кемгә кирәк соң бу сугыш, кемгә кирәк?..» [Тинчурин, 2007, б. 188]. Автор бөтендөнья сугышының халыкка никадәр чит булуын, кешеләргә нинди фаҗигаләр китерүен ача. Авыл егетләренең бер өлеше сугышка алына, икенче төркеме исә төрле юллар белән солдаттан калу юлларын эзли. Әлеге вакыйгаларда авыл яшьләре Исмәгыйль белән Сәрвәрнең бәхетсез мәхәббәте, һәлакәте сурәтләнә. «Сүнгән йолдызлар» пьесасының исеме дә – геройларның үлемен аңлата. Драмада Исмәгыйль күргән төш тә булачак фаҗигале вакыйгаларга ишарә итә: «...аждаһа төсле бернәрсә сызгырды да, йолдызларны сүндерә башладылар. Минем йолдызым да сүнде, мәхдүмнең дә, синең йолдыз да сүнде...» [Тинчурин, 2007, б. 86]. Мәгълүм ки, мифологик ышанулар нигезендә төш киләчәк язмышны күрү, яисә теге яки бу вакыйгаларны хәл итү чарасы буларак карала. К. Тинчурин пьесасындагы Аждаһа, болыт – сугыш, йолдызлар – бәхет

ролен башкара. Шул рәвешле әсәрдә матур хыяллар белән яшәүче, бәхеткә тулы хокуклы геройларның вакытсыз үлеменә сәбәпче булган сугышка, тормыш гаделсезлегенә басым ясала. Драмада табигать тарафыннан кимсетелгән, бөкре, ямьсез кыяфәтле мәхдүм Надир образы да игътибарга лаек. Пьесада ул рухи яктан көчле, горур, саф күңелле, әмма үзенең гариплегеннән авырлыклар, күңел газабы кичерүче шәхес буларак ачыла. Надирның төп эчке конфликты, фаҗигасе – аның теләге һәм чынбарлык арасында. Авылның иң чибәр кызы Сәрвәрне ярату аңа яшәү көче бирә, тормыш мәгънәсенә әйләнә. Герой хыялында туган бәхетен акылдан язган Сәрвәр белән аралашуда таба. Хыялында гына булса да бәхетле булу өметен җимергән чынбарлыкка карата протестын Надир үлеме белән раслый. Шул рәвешле, К. Тинчурин укучыга тирән газапланулар кичергән фаҗигале язмышлы ялгыз кеше образын тәкъдим итә. «Надир мәхдүм кебек гаять киеренке тетрәнүләргә, көчле психологик кичерешләргә ия герой татар драматургиясендә юк иде әле. Бу, һичшиксез, Тинчуринның зур табышы, театр сәнгатенә керткән зур яңалыгы иде» [Бәширов, 2007, б. 11].

Драманың һәр герое үз бәхетенә омтыла, ләкин аларның барысын да реаль тормышның кырыс чынбарлыгы чолгап алган. Күренә ки, К. Тинчурин мәхәббәт, гаилә мәсьәләсен ярлылар һәм байлар каршылыгы аша бирми, ә гашыйклар фаҗигасе ил күләмендә барган вакыйгаларга бәйләп аңлатыла. Иҗтимагый-сәяси шартлар хыялларны тормышка ашырып яшәргә ирек бирми. Татар яшьләренең бу хәлен драматург фаҗига буларак бәяли. Әлеге мәсьәләләр К. Тинчуринның «Ил» (1927) драмасында да күтәрелә. Вакыйгалар ерак үткәнне – алпавытлар, мирзалар хөкем сөргән, гади халык кол хәлендә яшәгән заманны үз эченә ала. Сыйнфый каршылыкларга корылган бу әсәрдә гомумкешелек кыйммәтләре, заман фаҗигасе бирелә. Мәхәббәт өчен көрәш сыйнфый тигезсезлеккә үрелеп китә, югары катлам вәкилләренең гади халыкны ни рәвешле җәфалавын ачуга юнәлтелә. Халык азатлыгына, матур киләчәккә омтылу, ил бәхете өчен көрәшү әсәрнең үзәген тәшкил итә. Автор гади халык азатлыгы, бәхете, бәйсезлеге өчен акрынлап көрәшкә күтәрелүче геройларга өстенлек бирә. К. Тинчурин ил агасы Туктамыш карт, Юлаучы Айтуган, Касыймхан образларына Җиһангир, Гаделгәрәй мирза кебек мәрхәмәтсез хаким сыйныфларны каршы куя. Драмада Туктамыш күпне күргән, акыллы, зирәк, кискен сүзле, шул ук вакытта изелү һәм төрлечә мәсхәрәләүләрне кабул итә алмаган ил агасы буларак тәкъдим ителә. Туктамышның бал кортларының тынычсызлануы, корт иленең күчеп китүе турындагы хәбәре крестьяннар арасында башланган уянуга, күтәрелүгә ишарәли. Сыйнфый көрәшне тирәнәйтеп күрсәтү өчен автор Юлаучы образын файдалана. Ул үзенең «чалгы хикәясе»ндә изелгән авыл халкына коралլы көрәш

тәртипләрен, ил күләмендә азатлык өчен башланган хәрәкәтләрнең активлашуын аңлата, кораллы күтәрелешкә чакыра. Пьесада Габделгәрәй мирзаның, аның приказчигы Җантимернең төрлечә мәсхәрәләүләренә протест рәвешендә Касыймханның алпавыт утарына ут төртүе геройны бунтарь-көрәшче дәрәҗәсенә күтәрә. Шушы хәлләрдән соң авыл кешеләре сыйнфый изүгә каршы оешкан төстәрәк протест белдерә башлыйлар. Бу бәрелешләр халык арасында социаль көрәшнең тууын хәбәр итә, ул дөньяга караш, әхлакый кыйммәтләр яссылыгында да бара. Айтуган, Касыймхан кебек ярлы халык вәкилләре, үзләрендә көрәшкә җитәрлек көч булмавына карамастан, кыю рәвештә гаделсезлеккә каршы чыгалар. Ләкин Туктамыш карт кулга алына, Айтуган күтәрелеш вакытында үтерелә. Биредә фаҗигалелек очраклы рәвештә, аерым бер шәхескә бәйле генә түгел, ә гаделлеккә каршы куелган явызлыкның көчлерәк булуыннан килеп туа. Айтуганның үлеме тормыш һәм язмыш изүе, байлык хуҗаларының гаделсезлеге нәтиҗәсе буларак бәяләнә. Әлбәттә, протест пассив характерда. Социаль киртәләрнең билгеле бер моментта көчлерәк булуы геройның фаҗигасен тудыра. Драматург аерым кешеләрнең шәхси язмышлары аша халык тормышының давыллы елларын, өмет чаткыларын, хезмәт кешесенең хыял-омтылышларын табигый җирлектә сурәтли.

К. Тинчуринның шигъри формада язылган бердәнбер сәхнә әсәре «Зар» (1922–1923) трагедиясендә яшәеш, яшәү мәгънәсе турында фәлсәфи караш тәкъдим ителә. Үз вакытында Г. Гали әсәргә «идеологический яктан зарарлы» дигән мөһер суга [Гали, 1924]. Әсәрдә Газраил, Газазил, Әҗәл, Һава, Адәм кебек образларга яңа мәгънә салына. Трагедиядә, мәсәлән, Газазил – иреккә, бәхеткә омтылыш символы буларак тәкъдим ителсә, Дәҗҗал аңа каршы куела.

«Г а з а з и л.
Янсын гомергә
Чын дуслык, ирек!
Һәм саф матурлык
Яшәгән чакта,
Яшәмәс коллык», –

ди ул [Тинчурин, 1986, б. 420].

Шәйтан исә җиһанда золым өстенлек итүен тели, Бәдбәхеткә бәла-казалар, хәсрәт, байлыкка табынучы Яэҗүҗгә (Капиталга) тәхет кирәк, Мәхәббәт иреккә омтыла, матурлыкны юкка чыгаручы Мәэҗүҗ (Милитаризм) сугыш тели, Ирек исә азатлык сорый.

Шул рәвешле, оҗмах халкы ике төркемгә – Газазилны куәтләүчеләргә һәм Дәҗҗал яклыларга аерыла. Адәм яратылгач исә хакимлеккә омтылган Дәҗҗал белән Газазил арасындагы каршылык тагы да кискенләшә. Дәҗҗал һәм аның тарафдарлары Адәмне үз максатларында файдаланып, явызлыкка өндиләр. Газазил Алла яраткан Адәмгә ак мәрмәрдән эшләнгән, матурлык символы булган Һаваны каршы куя. Мәхәббәтләре өчен Адәм белән Һава оҗмахтан куылгач, җирдә ачлыктан җәфа чиккән Адәм, Шәйтан котыртуына биреләп, кыр кәҗәсенең башына таш белән бәрә, кан коя. Кан коюның

нәтиҗәсе буларак, кешеләрнең гомере чикләнә. Кызганыч ки, җирдә дә матурлык табылмый. Адәмнәрне бер-берсенә каршы котыртып, Шәйтан йөри. Фән һәм техника казанышлары да Дәҗҗалга хезмәт итә. Әйләнә-тирәдә коллык, ачлык хөкем сөрә. Акрынлап җир өстендә «Төрле шахта һәм приискаларның галәмәтләре күренә. Уртада адәм сөякләреннән өелгән зур тау. Газраил шул тауның башында басып тора» [Тинчурин, 1986, б. 502].Техника белгече Мөһәндис «бер сулышта йөз мең адәм кыра торган» корал уйлап таба. Әмма Мөһәндиснең яңа коралы җирне юк итәргә өлгергәнче, изелгәннәр хакы өчен көрәшүче Газазил халыкны явызлыкка каршы көрәшкә күтәрә. Трагедия ахырында бары Шәйтан гына богаулы урынын калдырып кача. Димәк, азатлык, ирек өчен көрәш дәвам итә. А. Әхмәдуллин билгеләгәнчә, әсәрнең беренче өлешендә шәхеснең азатлыкка омтылышына, аның фәлсәфи якларын барлауга игътибар ителсә, икенче өлештә изелүчеләрнең изүчеләргә каршы көрәше алга чыга [Ахмадуллин, 2012, б. 223]. Авторга мифологик образларга таяну отышлы нәтиҗәләр бирә: иҗади фикерләү колачын киңәйтә, чор үзенчәлекләрен үтемлерәк бәян итү мөмкинлеген ача. Трагедиядә инкыйлаб мотивлары конкрет чагылыш таба.

К. Тинчурин заман кешеләрен, чорга хас үзенчәлекләрне эволюцион үсештә сурәтли. Тема һәм күтәрелгән мәсьәләләрнең күп булуы әдипне төрле жанр формаларына мөрәҗәгать итүгә, аларның мөмкинлекләрен иҗади файдалануга этәрә. Аның иҗатында якты киләчәккә өметләндергән көч, халык рухының үлемсезлеге алгы планга чыга. Әсәрләрендә шәхес һәм ил фаҗигасе җәмгыятьтәге тәртипләр аша ачыла. Пьесалар үзәгендә аерым бер кеше яшәеше генә түгел, ә халык, милләт язмышы.

**Әдәбият**

*Арсланов М.Г.* К. Тинчуринның тормышы һәм иҗат этаплары // Кәрим Тинчурин һәм татар сәнгате: Бөтендөнья фәнни-гамәли конференциясе материаллары. Казан, 2007.336 б.

*Ахмадуллин А.Г.* Татарская драматургия: история и проблемы. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. 329 с .

*Әхмәдуллин А.* Офыклар киңәйгәндә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002, 239 б.

*Бәширов Ф.* Ул кабызган учаклар мәңге янар // Тинчурин К.Г. Драмалар, комедияләр, хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. Б. 3–12.

*Гали Г.* Зар // Кызыл Татарстан. 1924. 29 май.

*Тинчурин К.* Әсәрләр: 3 томда. Т. 1. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 472 б.

*Тинчурин К.Г.* Драмалар, комедияләр, хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 351 б.

*Шәехов Л.М.* Татар шигъри трагедиясе. Казан: ТӘһСИ, 2016. 160 б.

***Миңнуллина Фатыйма Хәлиулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*
*minnullina77@mail.ru*